| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Әлмәт ав. **КАРАР**

«01» ноябрь 2023 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 15 ноябрендә Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Иске Әлмәт авылы, Октябрь урамы, 19 йорт адресы буенча Иске Әлмәт мәдәният йорты бинасында 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында яшәүче Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында үзара салым кертү һәм элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уздыруны билгеләргә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2022 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыенының 2022 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы карарына.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2020 елның 13 ноябрендәге 3 номерлы карарына;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыенының 2020 елның 13 ноябрендәге 4 номерлы карарына.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1 «2023 елда 73 430 сум 00 тиен (җитмеш өч мең дүрт йөз утыз сум 00 тиен) күләмендә гражданнарның үзара салым кертүдән трактор сатып алуга җыюдан калган

акчаларны «БЕЛАРУС 82.1» тракторын карап тотуга һәм «БЕЛАРУС 82.1» тракторы өчен запас частьләр сатып алуга кулланырга ризамы?»

3.2. «2021 елда гражданнарның үзара салым кертүдән янгынга каршы инвентарь сатып алуга дип җыюдани калган 71 872 сум 00 тиен (җитмеш бер мең сигез йөз җитмеш ике сум 00 тиен) күләмендә акчаны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылындагы күлне чистарту өчен кулланырга ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов